СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
28 октября 2015 года

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 19

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**2015 елның 28 октябрендәге**
**19 номерлы карарына**
**кушымта**

**Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында нигезләмә**

1. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга даими нигездә, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән киткәндә, 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, пенсиягә өстәмә түләү хокукы булганда пенсиягә чыкканда биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән ун тапкыр айлык акчалата бүләкләү күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләнә.

2. Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органы (алга таба - җирле үзидарә органы) тарафыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче зат, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, эштән киткәнче, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3. Җирле үзидарә органы бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү күләмен билгеләү өчен «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә (алга таба - финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

3.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка, пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү турында карар;

3.2. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның айлык акчалата бүләкләү турында белешмәсе;

3.3. дәүләт һәм (яисә) муниципаль вазыйфада һәм дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттә эш стажы турында җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте раслаган белешмә;

3.4. җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең һәм хәрби билетның күчермәләре;

3.5. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә, кирәкле башка документлар.

4. Җирле үзидарә органы әлеге нигезләмәнең 3 пункты нигезендә, пенсиягә чыгу сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү турында карар кабул ителгәннән соң, 5 календарь көн эчендә документлар тапшыра.

5. Финанс-бюджет палатасы әлеге нигезләмәнең 4 пункты нигезендә, җирле үзидарә органы тарафыннан документлар тапшырганнан соң 10 календарь көн эчендә Зеленодольск муниципаль районы Советы күрсәтелгән чыгымнарны каплауга Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан акча бүлеп бирү турында карар проектын җибәрә.

6. Финанс-бюджет палатасы карар кабул ителгәннән соң 20 календарь көн эчендә җирле үзидарә органына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү өчен бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр җиткерә.

7. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән белдерүләр нигезендә, пенсиягә чыкканчы, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләүне башкара.

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү бер тапкыр түләнә. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләгәндә яисә граждан пенсиягә чыкканнан соң һәм аннан соң муниципаль хезмәткә кергәндә, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен туктатканда яисә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү кабат түләнми.

Закон нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләнгән затларга яисә дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү пенсиягә чыгу сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасыннан киткәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләнми.